РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 22 июне** **Чистай шәһәре** **________80_________**

Чистай шәһәре Башкарма комитетының
«Стационар булмаган сәүдә объектларын
урнаштыру схемасын раслау турында»
2016 елның 27 июнендәге 96 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясын, «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы, «Стационар булмаган сәүдә объектларын муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 18 сентябрендәге 675 номерлы карарларын үтәү йөзеннән, Чистай шәһәре Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай шәһәре Башкарма комитетының «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2016 елның 27 июнендәге 96 номерлы карары белән расланган стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына өстәмәләр кертергә, кушымта нигезендә 90 - 95 пунктын тулыландырырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://chistopol.tatar.ru/) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ф.М. Садыйковка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты
җитәкчесе И.Ф. Рәхимов

Чистай шәһәре
Башкарма комитетының
2021 елның 22 июнендәге
80 номерлы карарына кушымта

Чистай муниципаль районының Чистай шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № т/б | Стационар булмаган сәүдә объектының урнашу урыны | Сатыла торган товарның ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объекты тибы | Сәүдә урынна ры саны | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 90. | Чистай шәһәре, К. Маркс ур., Бульвар Скарятин бакчасына керү юлында | азык-төлек товарлары (соклар, алкогольсез эчемлекләр, туңдырма) | зонт, суыткыч җиһазлары | 1 | сезонлы |
| 91. | Чистай шәһәре, Энгельс ур., стадион | азык-төлек товарлары (соклар, алкогольсез эчемлекләр, туңдырма) | зонт, суыткыч җиһазлары | 1 | сезонлы |
| 92. | Чистай шәһәре, Энгельс ур., стадион | баллы мамык | зонт, күчмә сәүдә җиһазлары | 1 | сезонлы |
| 93. | Чистай шәһәре, Энгельс ур., стадион | - | велосипедлар ны, роликларны, самокатларны , машиналарны прокатка алу пункты | 1 | сезонлы |
| 94. | Чистай шәһәре, Энгельс ур., Яшьләр скверы | баллы мамык, алкогольсез эчемлекләр, туңдырма | зонт, суыткыч, сәүдә җиһазлары | 1 | сезонлы |
| 95. | Чистай шәһәре, Энгельс ур., Яшьләр скверы | - | велосипедлар ны, роликларны, | 1 | сезонлы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | самокатларны, машиналарны прокатка алу пункты | | |